КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март г.Казань № 309

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карары белән расланган акчалары максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 июль, 648 нче; 2022 ел, 14 октябрь, 1100 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган акчалары максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегенә, 15 пункттагы «Россия Федерациясе Социаль иминият фондыннан» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны көчәйтү турында» 2003 ел, 11 апрель, 197 нче;

«Керемнәр һәм чыгымнар сметалары нигезендә финанслана торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучыларның эшмәкәрлек эшчәнлегеннән һәм табыш китерә торган башка эшчәнлектән алынган акча белән операцияләрне исәпкә алуны системалаштыру чаралары турында» 2003 ел, 18 апрель, 211 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Керемнәр һәм чыгымнар сметалары нигезендә финанслана торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучыларның эшмәкәрлек эшчәнлегеннән һәм табыш китерә торган башка эшчәнлектән алынган акча белән операцияләрне исәпкә алуны системалаштыру чаралары турында» 2003 ел, 18 апрель, 211 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 ел, 16 июнь, 323 нче;

«Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән башкарылырга тиешле бюджет йөкләмәләре исәпкә алына торган дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясе кодлары исемлеге турында» 2009 ел, 6 февраль, 71 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин